
# КИҢ ТАРМАКЛЫ МИЛЛИ ИҖАТ

Розалина Шаһиева



*Хәмит Латыйфның агач уймалары, ягъни агачны уеп ясаган сәнгате – меңьеллыклар буенча безне әйләндереп алган, тибрәтеп йоклаткан, йә кояшлы йорт, йә алтын бишек булып назлаган, йә тәгәрмәчле арба сыйфатында, йә уенчык ат булып дөнья гиздергән; яфраклары, бизәкләре, хуш исләре, сайрар кошларының чыңгылдавы белән йөрәкләрне җилкендергән урман белән тоташу хикмәте. Бу сәнгать – үзе бер зур тармак! Алтынсу йомшак каен такталарга махсус пычак яисә өтерге ярдәмендә уеп бизәк йөгертү, күңелләреңне биләп торган уйлар ташкынын сынландыру – ата-бабалардан калган, авылларда әле дә очраштыргалый торган хикмәтле һөнәр – хикмәтле мирас! Балачагыннан эшче-корымчылар, йорт салучылар, агач осталары арасында кайнашкан, җәй буе әтисе белән ат җигеп, утын агачы ташыган, бүрәнә ярган Хәмит бик иртә агач тану, агач бизәү стихиясенә кереп киткән. Ләкин биредә дә ул традицияләрне кабатлаучы һөнәр иясе – уемчы булып кына калмаган: күләмле сюжетларга, тематик серияләргә, фәлсәфи уйланулар дәрәҗәсенә күтәрелгән оста, яңа технологияләр тудыручы, үз алымнарын булдыручы рәссам булып формалашкан. Әле 1972 елда, мәшһүр агач уенчыклар төбәге – Мәскәү өлкәсенең Загорск районы Богородское авылында укыган чагында ук, Хәмит, биредә бары тик стандартка кергән темаларны кабатлый торган башкаручылар гына кирәклегән аңлап, укуын ташлаган һәм Уфага, сәнгать училищесына – махсус агач сырлап бизәү бүлегенә укырга кергән (1974-1978) еллар). Агачны нәкышләү һәм аңа чокып-уеп бизәк төшерү ысулларын анда җентекләп өйрәнгән. Инде беренче эшләре үк – «Шүрәле» панносы, Яр Чаллы шәһәрендәге балалар бакчасы, төрле җәмәгать биналары өчен башкарылган декоратив паннолары, ишекләр татар читеген каю техникасын хәтерләткән нечкә сырлы юлларның үзсүзле көйле хәрәкәтеннән гыйбарәт. Аларның максаты – «үрмәкүч оясы»н хәтерләткән сызым һавалы җанлы тиралек тудыру...*







«Сак-Сок». Панно. 2017 ел



«Яз». Тәлинкә. 2015 ел



«Безнең көй». Тәлинкә. 2005 ел

Агач бизәү өлкәсендә барган иҗади эшне Туймазы фарфор заводында эшләү этабы, чын мәгънәсендә милли сәнгать – нәкыш, гүзәл пастель техникасында башкарылган әсәрләргә чыгу чоры (1990 нчы еллар) туктатып тора кебек. Ләкин бу өлкәләрдә эшләү авторның композицион кыюлыгын арттыра; агач бизәү энергиясен абстракт геометрик кабатлаулар, йорт экстерьерын: капка, тәрәзә, ой кирәк-яракларын бизәү стиленнән мөстәкыйль мохит, образ тудыру стихиясенә алып кереп китә. Авторны сынчыга, нәккашкә әйләндерә.

2000-2002 елларда Хәмит Латыйф «Туран» милли-мәдәни фондында эшли. Бу чорда кыска гына вакыт эчендә гаҗәп үзгә, функциональ яктан күптөрле ихтыяҗларга туры килгән күләмле «уйма» серия пәйда була. Бу – агачтан ясалган сурәтле яссы тәлинкәләр, зур-зур декоратив сандыклар, ипи савытлары, интерьер җисемнәре, ярма


«Абый белән». Панно. 1977 ел


«Шүрәле». Агач. 1975 ел

салыр өчен көпшәләр, декоратив паннолар. Аларның йөрәге – тыгыз тутырылган гөл-яфрак, чәчәк орнаменты, аларны «кочып», тирәләп алган кеше сурәте: «Кубыз көе», «Урман көе», «Тукай», «Сакчы кошлар», «Матур кыз», «Гармунчы»... Шаймәрдән чорында* (2002-2003) бу җанлы катлам – кошлар, күбәләкләр, хайванәт – кояш-йолдыз, агар сулар, «тереклек агачы» сыман космогоник образлар белән керешеп китә... Останың агачны чокып, кисеп кенә, бизәкне өске якты яссылык белән астагы батынкы шәүләләрнең берләшүеннән туган тирәлектән гайре, өтергене тибрәтеп, биетеп, фактуралы бай мохит кабызу ысулы туып чыга.

2006 елларда Хәмит Латыйф яңа форма – юнып эшләгән түгәрәк озын вазалар – бал, май, кымыз савытлары, май төшерү гөбеләре сыман оригиналь шәкелләргә мөрәҗәгать итә. Аларны татар әкиятләре, мифологик образлар белән бизи, үзенең балачак хатирәләрен яңарта: самимилек һәм тәвәккәллек белән эшләнгән киң көпшәләр тышында нурлы кошлар, әкәм-төкәм, ак еланнар, юлбарыслар, шүрәлеләр, түбәтәйле батырлар, курайчылар. Урман җыры... Юка гына катлам органик буяу астында – әллә нинди шигъри хикмәт, фантастик манзаралар һәм әйберләрнең көнкүрештәге вазгыятенә тиң әверелешләр, үзгәрешләр могҗизасы. Тикмәгә генә алар бер мизгел эчендә Изге Болгар шәһәренең гөмбәзле төрбәләр панорамасына әверелмиләр! Бу чордагы тәлинкә-панноларда да – монументаль эрелек, саран серле сырлар, йөрәкне чымырдатырлык драматик чалымнар: «Юлбарыс», «Болын кошы», «Колын» һ.б. Мондагы алымнарның ачыклыгы – җәяле ук кадалган кебек тәгаен эзләр, төртке-сызымнар – хис тирәнлеген ача, образларның мәңгелегенә ишарә итә.

Нәкъ бу чорда Хәмит шулай ук яссы сувенир скульптуралар (15-20 см биеклектә)

* Шаймәрдән чоры – рәссамның Саба районының Шәмәрдән бистәсендә эшләгән еллары.






«Килен сандыгы». 2001 ел


«Болгар урманында». Капкачлы агач вазалар


Ике ягы да уелып, уртада пыяла калдырып эшләнгән ишек

һәм Африка битлекләре тәэсирендә туган «Битлекләр» сериясен иҗат итә. Болар агач фактураның мөмкинлекләрен, аның магик-мәҗүси тәэсир көчен ача торган иҗади эксперимент, бу традицион системага да авангард шаукымын кертеп карау, агачның материя буларак, универсальлеген исбатлау омтылышы булып кабул ителә. Күп кенә сувенирлар – кулай һәм, чын мәгънәсендә, бу җирнең күркәм традицияләрен ачучы истәлек булып кабул ителәләр: «Малай белән Шүрәле», «Бабай», «Кош тоткан кыз», төрек һәйкәлләрендәге кебек ананың йөрәге янында уелган бала – «Бала-ана», «Фәрештә» һ.б.

Хәмитнең иҗат кырлары бер-бере белән табигый берләшә, бер-беренә тәрәккыят дулкыны өсти, рәссамчылыгы «уймачылыгына», ә соңгысы нәкышенә, пастель һәм графикасына тәэсир итә, гомум камилләшүгә этәрә. Агачта тапкан кискен, үзсүзле, кулының энергиясен саклаучы, тормышның һөҗүменә бирешмәүче санаулы сызымнары, шулай ук аның пастель эшләренә дә кереп китә; «киртләч» агачлар, чатнаган куаклар арасында сурәтләнгән «матур авыллар», яшь-җилкенчәк, карт-коры образларына тәгаенлек, хакыйкать хисен өсти, шактый экзотик, яңача «үз тасвирына» ышаныч тудыра...

Мөстәкыйль бер сәнаигъ дөнья, иҗади бербөтен этнографик нигездә һәм рәссам дулкынлануы тәэсирендә туган «Агач уймалар» – үзе бер музей, авторның мәҗүси саф рухы, аның табигатьне тоя белүе, ихтыяр көченең күләмлелеге, иҗади сизгерлеге билгесе. Аларда – гүзәл дөнья кору сәләте; материяне буйсындыра белү, каты җисемнәрне үзләштерүнең кискен энергиясе. Алар рәссамның милли гаярьлеге, зирәклеге, татар дөньясының эшлекле вә гайрәтле иҗатчысы, гаҗәеп осталык иясе булуы турында сөйли.■